РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 20 декабре № 51

Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставының 6 статьясы нигезендә, күчемсез милек хокукына ия булучыларның һәм күчемсез милек объектлары белән идарә итү, файдалану, эш итү хокукын алырга теләүче затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү максатыннан, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендә кабул ителгән 20 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең картографик материалларына 1 нче кушымта нигезендә;

1.2 текстлы материалларга 2 нче кушымта нигезендә .

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.


Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2019 елның 20 декабрендәге
51 номерлы карарына
1 нче кушымта

Правила землепользования и застройки


# г.НИЖНЕКАМСК КАРТА ГРАДОСТРОИТЕЛЬНОГО ЗОНИРОВАНИЯ ТЕРРИТОРИИ

## Проект внесения изменений



# Правила землепользования и застройки

**Карта зон с особыми условиями использования территории муниципального образования "г. Нижнекамск"**
**(санитарно-защитные зоны и водоохранные зоны)**




**Лист 2 из 2**

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина

Түбән Кама шәһәр Советыны
2019 елның 20 декабрендәге
51 номерлы карарына
2 нче кушымта

Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә кертелә торган үзгәрешләр

Түбән Кама шәһәр Советының 2010 елның 22 декабрендә кабул ителгән 20 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. в пункте 12 статьи 19 слова «не менее двух и не более четырех» заменить словами «не менее одного и не более трех»; 19 статьяның 12 пунктында «кимендә ике һәм дүрттән дә артык түгел» сүзләрен «кимендә бер һәм өчтән дә артык түгел» сүзләренә алмаштырырга;

2. 21 статьяның 2-6 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

3. 25 статьяда:

3.1 Шәхси торак йортлар төзелеше зонасы Ж-1. территориаль зонасы җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының иң чик параметрлары, түбәндәге эчтәлекле таблица өстәргә:

| Параметрлар төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Күчемсез милекнең рөхсәт ителгән файдалануның өстәмә төрләренә карата параметрлар кыйммәте | |
|---|---|---|---|
| Кишәрлекнең минималь мәйданы | кв.м | 300 | |
| Урам фронты буйлап (юл) кишәрлекнең минималь киңлеге | м | 6 | |
| Кишәрлек төзелешенең максималь проценты | % | 60 | |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән минималь чигенеш (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) | м | 3 | |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | а) 0 - брандмауэр стенасы мәҗбүри булганда;<br>б) 1 – башка очракларда | |
| Кишәрлекнең арт чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | 1 | 1<br>(башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) |
| Бинаның максималь биеклеге (түбәнең иң биек урынына кадәр) | м | 6 | 6 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2,5 | 1,2 |

3.2. Ж-3 зонасының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Ж-3. 5-9 катлы урта катлы торак йортлар төзү зонасы»;

3.3 Ж-3 территориаль зонасындагы күчемсез милекне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләрендә. 5-9 катлы урта катлы торак йортлар төзелеше зонасы «- 5-8 катлы күпфатирлы торак йортлар;» сүзләрен «- 5-9 катлы күпфатирлы торак йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 «Ж-3 территориаль зонасы җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының иң чик параметрлары. 5-9 катлы урта катлы торак йортлар төзү зонасы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Параметрлар төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Кучемсез милекнең рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә карата параметрлар кыйммәте | |
|---|---|---|---|
| | | 5-9 катлы күпкатлы торак йортлар | рөхсәт ителгән файдалануның башка төрләре |
| Кишәрлекнең минималь мәйданы | кв.м | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы буенча | |
| Урам фронты буйлап (юл) кишәрлекнең минималь киңлеге | м | 48 | 15 |
| Кишәрлек төзелешенең максималь проценты | % | 30 | 60 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән минималь чигенеш (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) | м | 8,5 | 3,0 |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | 8,5 | 3,0 |
| Кишәрлекнең арт чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | 8,5 | 3,0 |
| Бинаның максималь биеклеге (түбәнең иң биек урынына кадәр) | м | 30 | 15 |

3.5. Ж-4 территориаль зонасындагы кучемсез милекнең рөхсәт ителгән файдалану төп төрләрендә. 9 каттан биегрәк күпкатлы торак йортлар төзү зонасы «- 10 каттан биегрәк күпфатирлы торак йортлар;» сүзләрен « 9 каттан биегрәк күпфатирлы торак йортлар» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 «Ж-4 территориаль зонасы җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының иң чик параметрлары. 9 каттан биегрәк күпкатлы торак йортлар төзү зонасы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Параметрлар төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | | Кучемсез милекнең рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләренә карата параметрлар кыйммәте | |
|---|---|---|---|
| | | 9 каттан биегрәк күпфатирлы торак йортлар | рөхсәт ителгән файдалануның башка төрләре |
| Кишәрлекнең минималь мәйданы | кв.м | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы буенча | |
| Урам фронты буйлап (юл) кишәрлекнең минималь киңлеге | м | 48 | 15 |
| Кишәрлек төзелешенең максималь проценты | % | 30 | 60 |
| Кишәрлекнең алгы чигеннән минималь чигенеш (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу линиясе белән билгеләнмәгән очракларда) | м | 9,5 | 3,0 |
| Кишәрлекнең ян чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | 9,5 | 3,0 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кишәрлекнең арт чикләреннән корылмаларның минималь чигенеше | м | 9,5 | 3,0 |
| Бинаның максималь биеклеге (түбәнең иң биек урынына кадәр) | м | 60 | 15 |

4. Д-2 территориаль зонасын рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре 26 статьясында. Сәламәтлек саклау һәм социаль билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы «- хайваннар өчен приютлар» сүзләрен өстәргә.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р.Долотказина